**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-02-22, факс (85552) 3-13-44, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
06.09.2018г

КАРАР
ПР-220

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 16 августында кабул ителгән “Дәүләт карамагында (муниципаль) булмаган коммерциясез оешмаларга субсидияләр бирү (дәүләт (муниципаль) милкенең капиталь төзелеш объектларына капиталь кертемнәрне тормышка ашыручы яки күчемсез милек объектларын дәүләт (муниципаль) милке итеп үзләштерүче субсидияләрдән тыш) турында” дип аталган ПР-132 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Актаныш муниципаль районы үсешенең өстенлекле юнәлешләрен тәэмин итүче чараларны тормышка ашыру, коммерциячел булмаган оешмаларның районның социаль-икътисадый үсеше бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән социаль проектларын эшләү һәм тормышка ашыруда актив катнашу өчен шартлар тудыру максатыннан, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 16 августында кабул ителгән ПР-132 номерлы “Дәүләт карамагында (муниципаль) булмаган коммерциясез оешмаларга субсидияләр бирү (дәүләт (муниципаль) милкенең капиталь төзелеш объектларына капиталь кертемнәрне тормышка ашыручы яки күчемсез милек объектларындәүләт (муниципаль) милке итеп үзләштерүче субсидияләрдән тыш) турында” дип аталган карарына үзгәрешләр кертергә һәм 2 нче пунктында түбәндәгечә күрсәтергә:

1.1. П. 2 Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан субсидия бирү турында Килешү (алга таба - килешү), шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы, Россия Федерациясе субъектының финанс органы, муниципаль берәмлекнең финанс органы тарафыннан билгеләнгән типлаштырылган форма нигезендәге килешүне (кирәк булганда) өзү турында өстәмә килешүнең төзелү шартлары һәм тәртибе;

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан 2018 елның 16 февралендә кабул ителгән ПР-21 номерлы “Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 16 августында кабул ителгән

ителгән ПР-132 номерлы “Дәүләт карамагында (муниципаль) булмаган коммерциясез оешмаларга субсидияләр бирү (дәүләт (муниципаль) милкенең капиталь төзелеш объектларына капиталь кертемнәрне тормышка ашыручы яки күчемсез милек объектларындәүләт (муниципаль) милке итеп үзләштерүче субсидияләрдән тыш) турында” карарына үзгәрешләр кертү турында” дип аталган карарны үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәренең хокукый мәгълүматлар тупланган рәсми порталында түбәндәге адрес буенча рәсми рәвештә бастырылган көннән башлап үз көченә керә: http://pravo.tatarstan.ru , һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайты: http:/aktanysh.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны тормышка ашыруны контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет житәкчесе вазифаларын башкаручы Л. Р. Сираева